# Искергән сүзләр.

- *Зур бәхетләр*
- *сызганып эшкә бирелгәннән килә,*
- *Аһ! Оят,хурлык,*
- *түбәнлекләр иренгәннән килә.*
- *Булса калдырмак берәү*
- *ушбу җиһанда изге ат,*
- *Тир белән тапсын ашарын,*
- *итсен, әлбәт, иҗтиһад.*
- *Һәр олугълар*
- *эшләгәнлектән олугълыклар таба,*
- *“Уйнады” дип бирмиләр*
- *ушбу җиһанда мәртәбә.*

- Г.Тукай.(1911)



- ушбу
- җиһан
- ижтиһад
- олугъ
- мөкаддәс

- *<u>өяз,сөңге</u>* -1нче төркем
- *<u>мәхәллә,ядрә</u>* - 2нче төркем
- *<u>инсан, аршын</u>* – 3 нче төркем
- *<u>арык, вә</u>* - 4 нче төркем

# Искергән сүзләр

- өяз
- мәхәллә
- сөңге
- ядрә
- аршын
- инсан
- арык
- вә

- Мәгънәләре буенча 1нче баганадагы сүзләр- вакыт узу белән кулланылыштан төшеп калган предмет яки күренеш исемнәре. Аларны ***тарихи сүзләр*** дип атыйлар. Аларны бары тик тарихи хезмәтләрдә яки шул чор матур әдәбияты әсәрләрендә кулланалар.
- Ә икенче баганадагы сүзләр – хәзерге көндә дә булган предметларның, күренешләрнең искергән атамалары. Аларны ***архаизмнар*** дип атыйлар.

- **Ишәк илә сандугач.**
- Ишәк сандугачны күрде дә, аның янына килеп: “Тыңла әле, дустым! Миңа сине, ул сайрарга бик маһир, дип мактадылар. Менә мин үз колагым илә синең тавышыңны ишетмәкче вә яхшы-начарлыгына үзем хөкем итмәкче булдым”, - диде.
- Сандугач, дәрхаль үзенең һөнәрен күрсәтергә башлап,әллә тагы мең төрле көйләргә борып сайрарга керәште.
- Ул,бер чут-чут итеп куеп, бер сызгыра, бер назиканә генә тавышын әкренләтеп, бер бөтен урманга вак кына ядрә сибелгән кеби яңгыратып җибәреп, ничек тә булса матуррак сайрарга тырыша иде. (Г.Тукай)

- **Имтияз алган бала.**
- Тырышты бу бала, чын ләззәт алды инде тәхсилдән;
- Югары булды урны “афәрин”нән һәм дә “тәхсин”нән.
- Ни кушсаң да укый алды, ни әйтсәң шуны язалды;
- Балаларның арасында үзенә “имтияз” алды.
- Беренче кәррә мөмтаз булса бер инсан туганнан соң,
- Фәхерле имтиязларны алыр үскәч тә аннан соң.

- ***“И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә-эш,***
- ***Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш.***
- ***Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,***
- ***Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел”***
-
- ***Г.Тукай***